**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1445**
**03.03.2021**

Башкарма комитетның 2020 елның 25 сентябрендәге 4913 номерлы карары белән расланган агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының «Шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 34/7 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 4/6 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 25 сентябрендәге 4913 номерлы карары белән расланган агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Муниципаль хезмәт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының административ-техник инспекция идарәсе (алга таба – АТИИ).

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризалар кабул итүне Башкарма комитет гамәлгә ашыра.»;

2) 1.3.3 пунктның бишенче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документлар әйләнеше формасында) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта uati@mail.ru аша электрон рәвештә.»;

3) 1.4 пунктта:

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр Советының «Шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 34/7 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 4/6 номерлы карары (алга таба – Шәһәр Советының 4/6 номерлы карары);»;

түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, ст. 4563);»;

4) 2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | 1) муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 12 пункты;<br>«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |

5) 3.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«АТИИ белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә Күчемсез милеккә һәм аның белән килешүләрне гамәлгә ашыруга хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган), салымнар, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматлар бирү турында запрос җибәрә.»;

6) 3.6.1-3.6.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. АТИИ белгече, яшел утыртмаларны тикшерү һәм кисү өчен түләүне исәпләү акты нигезендә (компенсацион яшелләндерү акчалата формада гамәлгә ашырылган очракта), агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә һәм утыртуга рөхсәт (алга таба – рөхсәт) проектын әзерләүне һәм аны имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне яки агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә һәм утыртуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе (алга таба – белдерү кәгазе) проектын әзерли һәм аны имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура тикшерү акты кергән вакыттан башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән рөхсәт проекты яисә имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән белдерү кәгазе проекты.

3.6.2. Башкарма комитет Җитәкчесе рөхсәтне имзалый һәм гариза бирүчегә бирү өчен АТИИ белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм АТИИ белгеченә җибәрелгән рөхсәт.»;

7) түбәндәге эчтәлектәге 3.6.3 пункт өстәргә:

«Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары белдерү кәгазен имзалый һәм гариза бирүчегә бирү өчен АТИИ белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм АТИИ белгеченә җибәрелгән белдерү кәгазе.»;

8) кушымтаны (белешмәне) 1 нче кушымтада каралганча бәян итәргә;

9) 1 нче кушымтаны 2 нче кушымтада каралганча бәян итәргә;

10) 3 нче кушымтада каралганча 5 нче кушымта өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 3 мартындагы
1445 номерлы карарына
1 нче кушымта

Кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы
һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | Farid.Salahov@tatar.ru |
| Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе башлыгы | 30-56-51 | Almaz.Hammatov@tatar.ru |
| Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе белгече | 30-57-77 | mky_ati@mail.ru |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 3 мартындагы
1445 номерлы карарына
2 нче кушымта

Агачларны һәм куакларны кисүгә,
ябалдашларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

______________________________________________
(муниципаль берәмлек җирле үзидарә органының исеме)

______________________________________________
(алга таба – гариза бирүче).
(юридик затлар өчен - тулы исеме, оештыру-хокук формасы, дәүләт теркәве турында мәгълүматлар;
физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары)

Агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт бирү турында
ГАРИЗА

Түбәндәге сәбәпләр буенча, Сездән ___________ адресы буенча үсә торган _____ данә (_________) агачны кисүне (ябалдашларын кисүне, күчереп утыртуны) килештерүне сорыйм:

1. агачлар минем милек хокукында булган бинаның фундаментына якын үсә, фундаментны җимерә;

2. агачлар бик карт, көчле җил вакытында ботаклары сынып төшә;

3. агачлар объект төзү зонасына эләгәләр;

4. башка сәбәпләр.

Компенсация төре: табигый формада / акчалата формада
(кирәклесенең астына сызарга)

Эшләрне башкарганнан соң агач калдыкларын мөстәкыйль рәвештә билгеләнгән срокларда чыгаруга һәм янәшә территорияне яшелләндерүгә йөкләмә алам.

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) шәхесне аныклаучы документлар;

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

3) участокның иң якындагы корылмаларга яки башка ориентирларга кадәр киселергә тиешле яшел утыртмалар билгеләнгән схемасы;

4) әгәр җир участогы күчемсез милеккә һәм аның белән килешүләрне гамәлгә ашыруга хокукларның Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса, җир участогына хокук билгели торган һәм хокук раслый торган документларның расланган күчермәләре;

5) биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга эләгә торган яшел утыртмалар киселгән очракта, расланган проект документлары;

6) агачлар киселә торган территорияләрнең хуҗалары белән яшел утыртмаларны кисү һәм күчереп утырту шартларын килештерү (кирәк булганда);

7) утыртмаларны утыртканда яки күчереп утыртканда, җир эшләрен башкаруга ордер ачып, инженерлык челтәрләре вәкилләре белән килештерү.

Сканерланган документларның төп нөсхәләрен тапшырырга йөкләмә алам.

| ____________ | ____________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 3 мартындагы
1445 номерлы карарына
3 нче кушымта

Агачларны һәм куакларны кисүгә,
ябалдашларын кисүгә яки утыртуга
рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Агачларны һәм куакларны кисүгә,
ябалдашларын кисүгә һәм утыртуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ

№ ______ «___» __________ 20____ ел

_______________________________________________________ заявка нигезендә яшел утыртмаларның урнашу урыны каралды.

20__ елның «____» ________________ _____ номерлы яшел утыртмаларны тикшерү акты нигезендә, Башкарма комитетның 20__ елның «____» ________________ _____ номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясе

____________________________________________________________________ адресы буенча
ЯШЕЛ УТЫРТМАЛАРНЫ КИСҮГӘ РӨХСӘТ БИРҮДӘН БАШ ТАРТА

Түбәндәге агачлар һәм куаклар ______________________________________ сәбәпле,
(баш тарту сәбәбен күрсәтергә)

| № т/б | Төре | Диаметры (см) | Саны | Факттагы торышы | Функциональ файдалану |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Барлыгы | | | | | |

Башкарма комитет Җитәкчесенең
беренче урынбасары ___________________

Белдерү кәгазен алды: _______________________________________________
(Ф.И.А.и., имза, дата)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева